| СОВЕТ<br>ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЗЕЛЕНОДОЛЬСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>СОВЕТЫ |
|---|---|

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

2015 елның 22 мае Зеленодольск шәһәре №526

2014 елда Зеленодольск муниципаль районы
бюджеты үтәлеше турында

«Зеленодольск муниципаль районы Финанс-бюджет палатасы» муниципаль учреждениесе җитәкчесе О. П. Дегтеваның 2014 елда Зеленодольск муниципаль районы бюджеты үтәлеше турындагы мәгълүматын тыңлап һәм фикер алышып, «Зеленодольск муниципаль районы Контроль-хисап палатасы» муниципаль учреждениесенең 2014 елда Зеленодольск муниципаль районы бюджеты үтәлеше турындагы хисапка бәяләмәсен исәпкә алып, Зеленодольск муниципаль районының 2014 ел бюджеты үтәлеше турындагы хисап гавами тыңлауларында фикер алышынды дип билгеләп , шулай ук Россия Федерациясе Бюджет кодексына, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законга, «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставының 92 статьясына, Зеленодольск муниципаль районы Советының Зеленодольск муниципаль районы бюджет процессы турында нигезләмәгә таянып, Зеленодольск муниципаль районы Советы **карар кылды**:

1. 2014 елда Зеленодольск муниципаль районы бюджеты үтәлеше турында хисапны керемнәр буенча 2 565 776 843,38 сум күләмендә, чыгымнар буенча 2 870 657 457,76 сум күләмендә, чыгымнарның керемнәрдән артуын 304 880 614,38 сум күләмендә һәм түбәндәге күрсәткечләр белән расларга:

– 2014 елда Зеленодольск муниципаль районы бюджеты кытлыгын финанслау чыганаклары әлеге карарга 1 нче кушымта нигезендә;

– 2014 елда Зеленодольск муниципаль районы бюджеты керемнәре күләмнәре әлеге карарга 2 нче кушымта нигезендә;

– 2014 елда бюджет ассигнованиеләрен бюджет чыгымнары классификациясенең бүлекләре һәм бүлекчәләре, максатчан статьялары һәм чыгымнар төрләре буенча бүлү әлеге карарга 3 нче кушымта нигезендә;

– 2014 елда Зеленодольск муниципаль районы бюджеты чыгымнарының ведомство структурасы әлеге карарга 4 нче кушымта нигезендә;

– 2014 елда күпфатирлы йортларга капиталь ремонт чараларын тәэмин итүгә җирлекләр бюджетларыннан бюджетара трансфертлар әлеге карарга 5 нче кушымта нигезендә.

– 2014 елда бюджет тәэмин ителешен тигезләүгә җирлекләр бюджетларына дотацияләр бүлү әлеге карарга 6 нчы кушымта нигезендә;

– 2014 елда граждан хәле актларын дәүләт теркәвенә алу вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга җирлекләр бюджетларына субвенцияләр әлеге карарга 7 нче кушымта нигезендә бүлү;

– 2014 елда хәрби комиссариатлар булмаган территорияләрдә беренчел хәрби исәпкә алуны гамәлгә ашыру вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга җирлекләр бюджетларына субвенцияләр бүлү
әлеге карарга 8 нче кушымта нигезендә;

– 2014 елда халыкка китапханә хезмәте күрсәтүне оештыруга, китапханә фондларының сакланышын комплектлауга һәм тәэмин итүгә, ял вакытын оештыру һәм җирлекләрдә яшәүчеләрне мәдәният оешмалары хезмәт күрсәтүләре белән тәэмин итү өчен шартлар тудыруга җирлекләр бюджетларыннан бюджетара трансфертлар бүлү әлеге карарга 9 нчы кушымта нигезендә;

– 2014 елда муниципаль хезмәткәрләрнең квалификациясен күтәрүне оештыруга җирлекләр бюджетларына бюджетара трансфертлар бүлү әлеге карарга 10 нчы кушымта нигезендә ;

– 2014 елда җирлекләр бюджетларына максатчан билгеләнештәге башка бюджетара трансфертлар бүлү әлеге карарга 11 нче кушымта нигезендә ;

– 2014 елда Башлыкларны матди яктан бүләкләүгә җирлек бюджетларына бюджетара трансфертлар бүлү әлеге карарга 12 нче кушымта нигезендә;

– 2014 елда муниципаль районнарның административ үзәкләре һәм шәһәр тибындагы поселоклар булып торучы муниципаль берәмлекләрнең башкарма комитетлары җитәкчеләрен матди бүләкләүгә җирлекләр бюджетларына бюджетара трансфертлар бүлү әлеге карарга 13 нче кушымта нигезендә;

– 2014 елда гражданнарның үзара салым акчаларын җәлеп итеп гамәлгә ашырыла торган җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җирлекләр бюджетларына бюджетара трансфертлар бүлү әлеге карарга 14 нче кушымта нигезендә;

– 2014 елда архитектура һәм шәһәр төзелеше сәясәте өлкәсендә җирлекләр бюджетларыннан бюджетара трансфертлар бүлү әлеге карарга 15 нче кушымта нигезендә ;

– 2014 елда юл-урам челтәрен норматив хәлгә китерү өчен җирлекләр бюджетларыннан бюджетара трансфертлар бүлү әлеге карарга 16 нчы кушымта нигезендә .

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының (http://pravo.tatarstan.ru) хокукый мәгълүматы рәсми порталында һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районы (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) сайтында урнаштырырга.

**Зеленодольск муниципаль районы**
**Башлыгы, Советы рәисе** **А. В. Тыгин**